| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.12.2024 Казан ш. № 294-ОД

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 221-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 221-ОД номерлы боерыгын «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 6 май карарына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 10 октябрендәге 1360 номерлы карарына туры китерү максатларында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 2023 елның 20 ноябрендәге 221-ОД номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 5 пунктчасында «амнистия яисә ярлыкау турындагы актларны кулланганда» сүзләрен «амнистия турында актларны яисә ярлыкау турында актларны кулланганда» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

«а» пунктчасында «хисаплылыктан өземтәләр» сүзләрен «белешмәләр» сүзенә алмаштырырга;

«б» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«б) Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Бюджет кодексының $160^1$ статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтүнең бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итүдә күрелгән чаралар турында Министрлык белешмәләре;»

«в» пунктчасында:

җиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгәннәргә карата амнистия турында акт яисә ярлыкау турында акт яисә Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтү мөмкинлеген югалта торган суд акты, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы тәмамлануга бәйле рәвештә дә (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданинның судтан тыш банкротлык процедурасы тәмамлануы турында Банкротлык турындагы белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (әлеге Тәртипнең 2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);»;

14 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Бюджетка түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында комиссия тарафыннан рәсмиләштерелгән акт Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры (алга таба – министр) тарафыннан имзаланган көннән алып 10 эш көне эчендә раслана.».

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының юридик бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары –
министр О.В. Коробченко